ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2 май, 2024 ел № 33/7

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында» Шәһәр Советы карары проекты буенча җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләрен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28, 44 статьялары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 92, 93, 94 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы турында» 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2006 елның 19 октябрендәге 15/4, 2007 елның 4 июлендәге 23/4, 2007 елның 25 декабрендәге 28/10, 2008 елның 29 февралендәге 30/7, 2009 елның 9 апрелендәге 40/6, 2009 елның 10 сентябрендәге 42/7, 2010 елның 31 мартындагы 47/7, 2010 елның 27 декабрендәге 7/6, 2011 елның 15 декабрендәге 15/7, 2012 елның 5 июлендәге 19/15, 2012 елның 20 декабрендәге 22/19, 2013 елның 29 августындагы 26/17, 2014 елның 21 февралендәге 29/17, 2014 елның 16 октябрендәге 33/17, 2015 елның 27 февралендәге 38/14, 2015 елның 23 июлендәге 41/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/10, 2017 елның 22 февралендәге 15/10, 2017 елның 10 августындагы 18/9, 2017 елның 15 декабрендәге 21/16, 2018 елның 27 апрелендәге 24/8, 2018 елның 11 декабрендәге 28/9, 2019 елның 1 августындагы 32/13, 2019 елның 6 декабрендәге 34/14, 2020 елның 17 июнендәге 40/3, 2020 елның 29 декабрендәге 4/7, 2021 елның 27 маендагы 7/6, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/5, 2022 елның 23 июнендәге 15/6, 2022 елның 26 декабрендәге 19/7, 2023 елның 5 маендагы 23/4, 2023 елның 25 октябрендәге 27/8 номерлы Карарлары редакциясендә) Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **9 статьяның 1 өлеше 11 пунктында** «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарга туры китереп шәһәр территориясендә планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

2) **9 статьяның 1 өлеше 30 пунктында** «җирле әһәмияттәге дәвалау – сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук » сүзләрен төшереп калдырырга;

3) **9 статьяның 1 өлеше 34 пунктын түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«34) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, муниципаль, шәһәр округында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

4) **9 статьяның 1 өлешендәге 40 пунктны**: «,шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләре;» сүзләре белән тулыландырырга;

5) **10 статьяның 1 өлеше 9 пунктын түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«9) муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;

6) **28 статьяның 2 өлеше 43 пунктын түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«43) муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;

**7) 28 статьяның 2 өлешендәге 55 пунктны** көчен югалткан дип танырга;

8) **28 статьяның 2 өлешендәге 68 пунктны**: «,шулай ук су объектларын рекреацион максатларда куллану кагыйдәләре;» сүзләре белән тулыландырырга;

9) **41 статьяның 3 өлеше 1 пунктында** «, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарга туры китереп шәһәр территориясендә планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

10) **41 статьяның 3 өлеше 1 пунктында** «җирле әһәмияттәге дәвалау – сәламәтләндерү урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук » сүзләрен төшереп калдырырга;

11) **41 статьяның 4 өлешенә түбәндәге редакциядә бәян итеп 4.1 пункт өстәргә**: «4.1) урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларыннан, региональ яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), шәһәр округы чикләрендәге планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, мондый исемнәрне үзгәртү, гамәлдән чыгару присвоение наименований элементам улично-дорожной сети (за исключением»;

12) **41 статьяның 13 өлеше 5 пунктында** «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

13) **41 статьяның 15 өлеше 2 пунктын түбәндәге** редакциядә бәян итәргә:

«2) массакүләм спортны үстерү һәм һәркемгә аның белән шөгыльләнү мөмкинлеген тәэмин итү, шәһәр территориясендә балалар – яшүсмерләр спортын

(шул исәптән мәктәп спортын) үстерү;»;

14) **XIII бүлек** исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«XIII бүлек. Муниципаль хокукый актларны кабул итү (нәшер итү), игълан итү һәм аларның үз көченә керү төрләре, тәртибе

15) **50 статьяның 7 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.Муниципаль хокукый актлар, Шәһәр Советының Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керүче салымнар һәм җыемнар турындагы карарларыннан тыш, әлеге уставта билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә.»

16) **50 статьяның 10 өлешендәге** «җиде көн» сүзләрен «ун көн» сүзләренә алыштырырга;

17) **50 статьяның 11 өлешен** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Оештыручысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче, кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр рәсми рәвештә халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.»;

18) **55 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«55 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка игълан итү һәм аларның үз көченә керү тәртибе.

1. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне рәсми рәвештә халыкка игълан итү – ул

1) тулы текстны рәсми рәвештә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында» (https://pravo.tatarstan.ru; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү таныклыгы ЭЛ ФС77-60244 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 17.12.2013 бирелгән) яки «Челнинские известия» (массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 7-4783, массакүләм коммуникацияләр һәм мәдәни мирасны саклау өлкәсендә законнарның үтәлешен күзәтчелек итү буенча федераль хезмәтнең Идел буе Идарәсе тарафыннан 30.11.2007 бирелгән), «Шәһри Чаллы» (массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәү турында таныклыгы ПИ №ТУ 16-01140 элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 24.09.2001 бирелгән) басма матбугатында бастырып чыгару;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://nabchelny.ru урнаштыру. ».

2. Гражданнарның «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»на керүләрен тәэмин итү өчен «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли, алар Яр Чаллы шәһәре, Хөсәен Ямашев исемендәге бульвар, 4/14 йорты, А корпусы адресы буенча урнашкан «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет учреждениесе бинасында урнашкан.

3. Муниципаль хокукый актның тулы тексты «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (pravo.tatarstan.ru) бастырылган очракта,

басма матбугатта күләмле график һәм таблицалы кушымталар күрсәтелмәскә мөмкин, бу хакта басма матбугатта хәбәр ителә.

4. Әгәр муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми рәвештә бастырып чыгарганда, норматив хокукый актның яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең төп нөсхәсе белән чагыштырганда хаталар, башка төгәлсезлекләр булса, шул ук басмада хокукый акт кабул иткән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органының яки килешүгә кул куйган җирле үзидарәнең вазыйфаи затының төгәлсезлекне төзәтү турында рәсми хәбәре һәм муниципаль хокукый актның яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең тиешле нигезләмәләренең чын нөсхәсе бастырылырга тиеш.

5. Әлеге Уставның 50 статьясының 11 өлешендә күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкача билгеләнмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.».

2. Әлеге Карар, үз көченә керү гамәлдәге законнар белән башка вакытта каралган аерым нигезләмәләреннән тыш, матбугатта рәсми басылган көннән үз көченә керә.

3. Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г. Мәһдиевка әлеге Карарны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә тапшырырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Россия Федерациясе Юстиция Министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан 2024 елның 21 маенда теркәлде. Дәүләт теркәве номеры RU163020002024001.